ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 сентябрь 2015 ел № 5205

«Татарстан Республикасы Җир Кодексының 32.1 статьясы нигезендә бушлай җир участоклары алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү һәм гражданнарга җир участокларын өлешле милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 11 сентябрендәге 5496 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.10, 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә бушлай җир участоклары алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү һәм гражданнарга җир участокларын өлешле милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 11 сентябрендәге 5496 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

2) карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 6 пункты, «Россия Федерациясендә Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә»;

3) карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1. Җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга»;

4) карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага административ

регламентны «Интернет» челтәрендә тиешле мәгълүмати системаларда һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен «Мәгълүмати технологияләр үзәге» МАУга җибәрергә».

5) карарның 4 пунктын төшереп калдырырга;

6) 1 нче кушымтадагы «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә бушлай җир участоклары алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертү һәм гражданнарга җир участокларын өлешле милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» сүзләрен «Җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентынты» сүзләренә алмаштырырга;

7) 2 нче кушымтада 2.1 пунктчасының 3 баганасында «РФ Җир кодексының 28 статьясының 2 пунктындагы 2 абзац» сүзләрен «РФ ҖК 39.5 статьясының 6 пункты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Абдуллин